Марсель Әхмәтҗанов

# Болгар теленең язмышы
# (Эпиграфика материаллары буенча)

Алтын Урда дәүләте дәверендә Урта Идел буенда сакланган кабер ташларының теле XVIII гасыр башыннан бирле фәнни җәмәгатьчелекне кызыксындырып килә.

Иң башлап бу эшкә 1722 нче елда татар ахуны Кадер-Мөхәммәт Сүнчәләев һәм Казан шәһәренең тылмачы Йосыф Ишбулатов керешәләр[1]. Алар тарафыннан элеккеге Болгар шәһәре зиратындагы иллеләп ташның язулары күчереп алына. Аларның кульязмасы нигезендә урыс һәм Европа галимнәре эпитафия текстлары буенча фәнни хезмәтләр бастырып киләләр. Ләкин икенче бер татар галиме — Хөсәен Фәезхановның ачышына кадәр бу ташларның телен рәтләп аңлый алмаганнар. Галим 1863 нче елда Болгар шәһәрлеге тирәсендәге авылларда XIII-XIV йөзләрдән сакланып калган кабер ташларындагы текстларның бер өлеше теле ягыннан чуваш теленә якын булганлыгын ача. [2]

Аның бу ачышын миссионер Н.И.Ильминский, Н.И.Ашмарин һәм Н.Ф.Катановлар үз карашларына таяныч итеп файдаланалар. Татар галимнәре бу чордан калган эпиграфик истәлекләрне махсус өйрәнү эшенә керешмичә, фәкать аларны барлау, текстларны күчереп алып, бастырып чыгару юлында йөриләр. Шиһабетдин Мәрҗани, Ризаэтдин Фәхретдин, Гайнетдин Әхмәров кебек тарихчылар үзләренең хезмәтләрендә XIII-XIV гасыр Идел буе мөселман эпитафияләренең текстларын барлауга заманында өлеш кертәләр.

Мәгълүм сәбәпләр аркасында XIII-XIV гасыр Урта Идел буе мөселман эпиграфикасының тел материаллары белән кызыксыну 1910-1940 елларда беркадәр сүрелә. Бу эшкә 1940 елдан соң тарихчы Әхмәт Булатов, археолог Н.Ф.Калинин, тюрколог С.Е.Малов керешәләр. Бераз соңгарак, 1946 елдан, татар эпиграфик истәлекләрен өйрәнүне Һарун Йосыпов башлый. Аның фәнни-практик эшчәнлеге галимнең бай эчтәлекле мәкаләләрендә һәм 1960 елда дөнья күргән “Введение в булгаро-татарскую эпиграфику” исемле күләмле монографиясендә ачыла.

1972 елдан XIII гасыр эпиграфик истәлекләрен һәм аларның телен өйрәнүгә филология фәннәре докторы Фәрит Хәкимҗанов кереште. Аның эзләнүләре нәтиҗәсендә күп санлы яңа эпиграфик истәлекләр табылып укылды һәм текстларның теленә лингвистик аңлатма бирелде. Урта гасыр татар эпиграфик истәлекләрен өйрәнү эшенә 1980 елдан соң Болгар шәһәре музейтыюлыгы мөдире Җәмил Мөхәммәтшин кушылды. Аның бу темага баглы берничә мәкаләсе һәм Ф.Хәкимҗанов белән берлектә язылган монографиясе басылды. 1988 елда Әнкарада төрек филологы Талат Текинның татар галимнәре хезмәтләреннән файдаланып язылган китабы дөнья күрде.[3] Шул ук елларда Будапештта венгр галиме Рона Ташның XIII-XIV гасыр Урта Идел буе мөселман эпитафияләре текстлары телен өйрәнүгә багышланган китабы һәм мәкаләләре басылганы мәгълүм булды һ.б.

Кыскача гына ясалган күзәтүләрдән үк XIII-XIV гасырларда, Алтын Урда дәверендәге Урта Идел регионы мөселман кабер ташларын һәм аларның телен өйрәнүгә багышланган бай әдәбият барлыгы күзгә ташлана. Нәрсәсе

белән галимнәр игътибарына шулай лаек булдылар соң әлеге регионның эпиграфик истәлекләре?

Барыннан да бигрәк, Урта Иделнең XIII-XIV гасырдагы этносәяси тарихы өчен алар бердәнбер җирле язма чыганаклар хезмәтен үтиләр. Аларның текстларында Урта гасырларда Болгар олысының социаль бүленеше, теле, тарихы, географиясе, икътисади бәйләнешләре, мәгърифәте, сәнгате буенча кыскача мәгълүматлар бар. Бу проблемаларның барысына да тукталып үтү безнең өчен үзмаксат итеп куелмады.

Максатыбыз шушы эпитафия теле материалы нигезендә Урта Иделдә барган тел вәзгыятенә бәя бирүдән гыйбарәт.

Х.Фәезхановның Болгар олысының эпитафияләре теле буенча 1863 елда ясаган ачышыннан соң, XIII-XIV гасырларда яшәгән "болгар теле — чуваш теленең элгәресе", дигән караш Русия һәм Европа галимнәре арасында киң җәелде. Һәм бүгенге көндә дә нигездә шул фикер яшәп килә әле.

Татар тарихчысы Һ.Йосыпов, 1946-1960 елларда татар эпиграфикасы текстларын кыр-экспедиция шартларында туплап, аларны тарихи-лингвистик өйрәнү нәтиҗәсендә, XIII-XIV гасыр мөселман кабер ташларын һәм типологик, һәм лингвистик җәһәттән ике стильгә бүлеп карый.

I стиль кабер ташлары барлык материалның 10% чамасын тәшкил итә дип гомән ителә.

II стильгә караганннары 90% ка җитә дип санала.[4]

Һ.Йосыпов I стиль ташлардагы текстларга тел ягыннан түбәндәгечә якын килә. Бу төркемгә тулаем <u>гарәп телендәге, гарәп һәм яңа болгар телендәге</u>, янә дә <u>яңа болгар телендәге текстлар</u> керә дип санала.[5] Аның "яңа болгар теле" дигәне татар теленә туры килә. II стиль ташларга — <u>иске болгар һәм яңа болгар тел элементлары белән язылган текстлар; гарәп һәм иске болгар телендә язылган текстлар</u> керәләр.[6] Галимнең <u>иске болгар теле дигәне</u> — чуваш теле элементлары белән язылган текстларга туры килә.

Төп нәтиҗә XIII-XIV гасырлардан калган татар телендәге ташларның теле иске болгар теленең эволюциясе нәтиҗәсендә барлыкка килгән дигән фикергә кайтып кала.

Һ.Йосыповтан соң бу мәсьәләгә мөнәсәбәттә филолог Ф.Хәкимҗанов яңа концепция тәкъдим итте.[7] Ул үзенең хезмәтендә XIII-XIV гасырдан калган болгар ташларының теле үле эпитафия теле булган дигән нәтиҗәгә килә.[8] Аның фикеренчә, ташларда Болгар олысында яшәгән болгарларның җанлы теле чагылмый: "Разговорный язык волжских булгар, по-видимому, не нашли отражения в эпитафиях".[9]

Әлеге концепция буенча болгар теленең төрле диалектларының катнашы белән шәһәрдә (Болгарда) "гомум халык әдәби теле" барлыкка килә, һәм бу телдә болгар галимнәре, шагыйрьләре үзләренең әсәрләрен иҗат иткәннәр дигән фикер алга сөрелә. Соңыннан бу шәһәр сөйләше Идел буе төрки теленә төзүче элемент буларак керә.[10] Галим бу хезмәтендә Идел буенда болгар телендә язылган эпитафия текстлары булуын һәм аларның чуваш теленә кардәшлеген таный.[11] Шулай ук, Ф.Хәкимҗанов үзенең хезмәтендә болгар теленең, төрки тел элементлары керә барып, Идел буе төркисенә кушылып китүе хакында яза.

XIII-XIV гасыр мөселман кабер ташларындагы текстларның телен тикшерүдә татар галимнәре Х.Фәезханов, Һ.Йосыпов һәм Ф.Хәкимҗановлар-

ның хезмәтләре төп нигезне тәшкил итәләр. Бүтән барлык галимнәрнең дә хезмәтләре аларның фәнни казанышларына һәм ачышларына нигезләнә һәм киләчәктә башкалар да алар туплаган бай материалга таянып эшләрләр.

Әлеге галимнәрнең Урта гасыр Идел буе эпиграфика теле турындагы карашларына бүгенге көндә башка яссылыктан килергә дә мөмкин.

Һ.Йосыпофның "иске болгар теле"нең эволюциясе нигезендә "яңа болгар теле", ягъни татар халкы теле килеп чыгуы теориясе филологик аналогияләргә ия түгел. Югыйсә, болгар теленә кардәш булган чуваш теленең үсеше татар теленә якынаю ягына барыр иде. Ләкин алай була алмый. Ф.Хәкимҗановның болгар теленең эпитафия материалы нигезендә, диалектлардан шәһәр койнэсына, аның аркылы Идел буе төркисенә, ягъни татар теленә үсеп җитү фикере башкача чишелешне сорый торган мәсьәлә кебек күренә. Бу чишелешне без яңача күз алдында тотабыз.

Мәсьәләне чишү өчен С.Малов, Һ.Йосыпов, Ф.Хәкимҗанов, ӘБулатов, Җ.Мөхәммәтшин хезмәтләрендәге текстларны җәлеп иттек.[12]

Әлеге куелган мәсьәләнең чишелеше Урта Иделдә XIII-XIV гасырларда булып узган этник процессның барышын ачыклау өчен мөһим. Аерым алганда, бүгенге Идел-Урал буе татарларының этник тарихында болгар компонентының тоткан урынын билгеләү һәм мөселман болгар тарихи-мәдәни мирасының варисларын ачыклау таләп итеdә.

XIII-XIV гасыр Урта Идел буе мөселман эпитафиясен өйрәнүче галимнәрнең хисаплавына караганда, аерым кисәкләре генә калган кабер ташларын да санасаң барлыгы 400 дән артык истәлек мәгълүм.[13] Хезмәтләре искә алынган галимнәрнең басмаларыннан бу мәкаләдә 161 эпитафия тексты файдаланылды.

Мәгълүм булганча, Татарстандагы татар халкының этник тарихында регионның өч төбәгенең үзенчәлекләре бар. Болар:

I. Кама аръягы, әүвәлге Болгар дәүләтенең һәм 1243 елдан соң Болгар олысының үзәк җирләре. Уң як Иделнең Тәтештән түбән ягы һәм Кама артының Уфага, көньякта Самарага кадәр булган җирләре керә.

II. Тау ягы — Болгар дәүләте һәм Болгар олысының провинциясе, Иделнең уң ягы, нигездә, Тәтеш шәһәре киңлегенә кадәр керә.

III. Казан арты — Идел, Кама, Нократ елгалары арасындагы өлкә, беркадәр төньякта Киров шәһәре тирәләренә кадәр сузылган җирләр. Шушы киң географик регионда XIII-XIV гасырларда Болгар олысының төньягында, урыны-урыны белән әүвәлге Болгар дәүләтенең халкы яшәгән. Кайбер Мәскәү тарихчыларының: татарлар болгарларны 1236 елда кырып бетергәннәр дип матбугат битләрендә ясаган чыгышлары, XIII-XIV гасырлар эпиграфик материаллары нигезендә дөреслеккә туры килми.

Файдаланылган фәнни басмаларда тикшерелә торган материал яңа болгар, иске болгар, болгар диалектлары теле дигән терминнар белән тәгаенләнә. Безне бу бүленеш канәгатьләндерми. Шунлыктан, тел ягын тикшергәндә түбәндәге принциплардан чыгып эш итәбез. Билгеле, һәр кабер ташында Коръән кәлимәләре гарәп телендә бирелә, ләкин шул вакытта мәрхүмнең үлү тарихы язылган текстлар болгар һәм татар телләрендә дә языла. Шунлыктан, эпитафия текстының теле турында сүз алып барганда анда мәрхүмнең үлү тарихы язылган күрсәткечләр, тел принцибы, билгеләмә була. Димәк, текстлар:

1. Болгар телендә;
2. Татар телендә;

3. болгар-татар, гарәп катнаш телләрендә;

4. гарәп телендә — язылганнар.

Шушы дүрт төрле телдәге текстларның таралыш географиясен өч тарихи өлкәгә (Кама аръягы, Тау ягы һәм Казан арты) нисбәттә бүлеп карыйк:

| Телләр | Кама аръягы | Тау ягы | Казан арты | Барлыгы |
|---|---|---|---|---|
| Болгар теле | 83 таш | 14 таш | 25 таш | 122=76% |
| Татар теле | 21 | | | 21=13% |
| Болгар-татар теле | 4 | 1 | | 5=3% |
| Гарәп теле | 11 | | 2 | 13=8% |
| Барысы | 119 | 15 | 27 | 161=100% |

Таблицада күренгәнчә, татар телендәге ташлар, күбрәк, Кама аръягы зонасында сакланганнар. Димәк, болгар телендәге ташлар барлык материалның 76 %, татар телендәге 13%, катнаш телдә 3%, гарәп телендә 8% тәшкил итәләр. Казан артындагы Ямәширмә (1382 ел) һәм Нырсы (1399) авылларында сакланган татар телендәге текстларны (2 таш) бу исемлеккә традиция буенча гына кертергә мөмкин, чөнки 1360 елдан соң Казан артында кискен этник үзгәрешләр чоры башлана. Әлеге ике таш китерелгән таблицага кертелмәде.

Катнаш болгар-татар телендәге текстлы ташлар да нигездә Кама аръягында сакланалар.

Казан артында гарәп телендә язылган бер эпиграфик текст Кабан күле буендагы Архирей дачасы булган җирдән алынган. Ул истәлек Болгар олысы белән идарә иткән, 1380 елларда үлгән Эчкеле Хәсән солтан ташы.[14] Гарәп телендә язылган текстлы икенче таш та, шул ук Архирей дачасы булган җирдә табылган. (Ул Казанда, берләштерелгән Дәүләт музеенда саклана). Ике таш та бер үк стильдә эшләнгәннәр.

Бу фактлар Тау ягы һәм Казан артында да 1360 елларга кадәр болгар халкы яшәгәнлеген һәм анда аларның телләрендә зур диалект үзенчәлекләре юклыгын раслыйлар.

Хәзер Кама аръягындагы эпитафия текстларының тел җәһәтеннән географик бүленешен күзәтеп үтик. Әлеге регионны XIV гасырда нигездә дүрт сәяси-административ үзәккә бүлеп өйрәнергә мөмкин:

Хәзерге Болгар шәһәре һәм аңа якын булган зона—төбәк;

Җүкәтау шәһәре (хәзерге Чистай шәһәре тирәсе) һәм аңа якын төбәк;

Бүләр шәһәре һәм аның тирәсе;

Ык-Агыйдел елгалары арасы.

Шул бүленешнең таблицада чагылышы:

| Телләр | Болгар | Җүкәтау | Бүләр | Ык-Агыйдел | Барысы |
|---|---|---|---|---|---|
| Болгар теле | 36 | 26 | 20 | 1 | 83 |
| Татар теле | 15 | | 1 | 5 | 21 |
| Болгар-татар | 2 | 2 | | | 4 |
| Гарәп теле | 6 | | 4 | 1 | 11 |
| Барысы | 59 | 28 | 25 | 7 | 119 |

Китерелгән таблицадан күренгәнчә, Кама аръягында 1280-1360 еллар арасында Болгар шәһәре һәм аның йогынтысы кергән җирләр (бүгенге Спасс,

Әлки, Чардаклы, Олы Тархан төбәкләре) олыс үзәген тәшкил итәләр һәм анда татар телендәге ташлар тупланышы да шактый зур. Бүләр шәһәре төбәгендә (өлешчә Алексеевск, Аксубай, Балынгүз, Норлат төбәкләре) татар телендәге ташларның иң аз булганлыгы күренә. Җүкәтау зонасында (Чистай, Түбән Кама һәм, өлешчә, Алексеевск) саф татар телендәге таш мәгълүм булмаса да, болгар-татар телендәге ике таш бу үзәктә татар теле барлыгына дәлил булып хезмәт итә.

Ык-Агыйдел арасындагы таш текстлары анда татар теле хакимлек итүенә дәлил булып хезмәт итәләр.

Таблицадагы саннар — татар теленең Урта Иделгә Кама аръягында беренче булып керә башлаганының күрсәткече. Монда болгар теленнән бигрәк татар теленең тәэсире үсү күзәтелә.

Кама аръяндагы татар телендә
язылган кабер ташларының исемлеге

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | 6.../12... | Болгар шәһәре | Х.2[15] | — | №1 таб. |
| 2. | 711/1311 | Болгар шәһәре | Х.2. | — | №2 таб. |
| 3. | 714/1314 | Олы Тархан авылы | Х.2. | — | №4 таб. |
| 4. | 714/1314 | Болгар шәһәре | Х.3[16] | — | №2 таб. |
| 5. | 717/1317 | — ,, — | Х.2. | — | №5 таб. |
| 6. | 724/1323 | — ,, — | Х.2. | — | №6 таб. |
| 7. | 728/1328 | Казан музее | Х.2. | — | №7 таб. |
| 8. | 734/1333 | Болгар шәһәре | Х.2. | — | №8 таб. |
| 9. | 742/1341 | Болгар шәһәре | Х.2. | — | №9 таб. |
| 10. | 743/1342 | Уфа музее | Х.2. | — | №10 таб. |
| 11. | 745/1345 | Иске Рәҗәп ав. | Х.2. | — | №11 таб. |
| 12. | 747/1346 | Уфа музее | Х.2. | — | №12 таб. |
| 13. | 750/1349 | Татар Калмаюры ав. | Х.2. | — | №13 таб. |
| 14. | 751/1350 | — ,, — | Х.2. | — | №14 таб. |
| 15. | 754/1353 | — ,, — | Х.2. | — | №15 таб. |
| 16. | 758/1357 | Яңа Дума ав. | Х.2. | — | №16 таб. |
| 17. | 759/1357 | Татар Калмаюры ав. | Х.2. | — | №17 таб. |
| 18. | ? | Урсай ав. | Х.2. | — | №21 таб. |
| 19. | ? | — ,, — | Х.2. | — | №22 таб. |
| 20. | ? | Татар Калмаюры ав. | Х.2. | — | №23 таб. |
| 21. | ? | Ямбакты ав. | Х.2. | — | б.89 |

Китерелгән таблица татар телендәге эпитафия текстларының 1340 елдан соң сизелерлек арта баруын күрсәтә.

Кама аръягындагы болгар телендә
язылган кабер ташларының исемлеге

| № | Һиҗри дата | Милади дата | Кайда куелган | Чыганак | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | 687 | 1288 | Болгар ш. | Ю[17] | — | №6 таб. |
| 2. | 690 | 1291 | —,,— | -,,- | — | №3 таб. |
| 3. | 694 | 1294 | —,,— | -,,- | — | №5 таб. |
| 4. | 699 | 1299 | —,,— | Х.М.[18] | — | №5 таб. |
| 5. | 700 | 1300 | Саурыш ав. | М.-ЭВ.[19] | — | №2 -б.42 |
| 6. | 705 | 1305 | Болгар ш. | Ю. | — | №39 таб. |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 7. | 706 | 1307 | Ташбилге ав. | Х.1[20] | — | №2 таб. |
| 8. | 709 | 1309 | Болгар ш. | Х.1 | — | №3 таб. |
| 9. | 710 | 1310 | Саурыш ав. | М.-ЭВ. | — | №2 -б.43 |
| 10. | 714 | 1314 | Кизләү ав. | Х.2 | — | №24 таб. |
| 11. | 715 | 1315 | Ташбилге ав. | Х.2. | — | №25 таб. |
| 12. | 716 | 1316 | ? | Ю. | — | №14 таб. |
| 13. | 716 | 1316 | Архангельское ав. | Ю. | — | №13 таб. |
| 14 | 717 | 1317 | Ямбакты ав. | Х.2. | — | №26 таб. |
| 15. | 717 | 1317 | Барское Енарускино ав. | Х.1. | — | №5 таб. |
| 16. | 717 | 1317 | Ильдеряково ав. | Б[21] | — | №4 таб. |
| 17. | 718 | 1318 | Иске Баллыкүл ав. | Х.2. | — | №27 таб. |
| 18. | 718 | 1318 | Иске Роман ав. | Х.1. | — | №6 таб. |
| 19. | 718 | 1318 | Иске Ибрай ав. | Б. | — | №3 таб. |
| 20. | 720 | 1320 | Иске Роман ав. | Х.1. | — | №7 таб. |
| 21. | 720 | 1320 | Балынгуз (Бүләр) | Х.М. | — | №2 таб. |
| 22. | 720 | 1320 | Болгар ш. | Х.2. | — | №28 таб. |
| 23. | 722 | 1322 | Болгар ш. | Ю. | — | №17 таб. |
| 24. | 723 | 1323 | Иске Роман ав. | Х.1. | — | №8 таб. |
| 25. | 724 | 1324 | Урта Чаллы ав. | Х.2. | — | №29 таб. |
| 26. | 725 | 1324 | Иске Роман ав. | Х.2. | — | №30 таб. |
| 27. | 724 | 1324 | Ямбакты ав. | Х.1. | — | №10 таб. |
| 28. | 724 | 1324 | Коры Көрнәле ав. | Х.1. | — | №11 таб. |
| 29. | 726 | 1325 | — ,, — | Х.1. | — | №12 таб. |
| 30. | 726 | 1325 | Иске Баллыкүл ав. | Х.2. | — | №32 таб. |
| 31. | 726 | 1325 | — ,, — | Х.2. | — | №33 таб. |
| 32. | 727 | 1326 | Болгар ш. | М.-ЭВ. | — | №2. -б.46-47. |
| 33. | 728 | 1327 | Болгар ш. | М.-ЭВ. | — | №2. -б.48. |
| 34. | 730 | 1329 | Болгар ш. | Х.1. | — | №13 таб. |
| 35. | 731 | 1330 | Чистай ш. | Х.2. | — | №34 таб. |
| 36. | 733 | 1333 | Иске Роман ав. | Х.1. | — | №15 таб. |
| 37. | 734 | 1333 | Чув.Ялтаны ав. | Х.2. | — | №35 таб. |
| 38. | 736 | 1335 | Чистай ш. | Х.1. | — | №17 таб. |
| 39. | 736 | 1335 | Яңа Чишмә ав. | Б. | — | №2 таб. |
| 40. | 740 | 1341 | Әшнәк ав. | Х.1. | — | №18 таб. |
| 41. | 747 | 1346 | Яңа Чуваш Адәме ав. | Х.1. | — | №20 таб. |
| 42. | 748 | 1347 | Ильдеряково ав. | Б. | — | №6 таб. |
| 43. | 748 | 1347 | Яңа Дума ав. | Б. | — | №12 таб. |
| 44. | 749 | 1348 | Татар Талкышы ав. | Х. | — | №21 таб. |
| 45. | 750 | 1349 | Саурыш ав. | Х.2. | — | №36 таб. |
| 46. | 750 | 1349 | Тубылгытау ав. | Х.2. | — | №37 таб. |
| 47. | 752 | 1351 | Карматбаш ав. | Б. | — | №15 таб. |
| 48. | 758 | 1356 | Иске Ибрай ав. | Х.2. | — | №38 таб. |
| 49. | 759 | 1356 | Ильдеряково ав. | Б. | — | №5 таб. |
| 50. | 760 | 1358 | Арбузов Баран ав. | Х.1. | — | №25 таб. |
| 51. | 7.. | 13.. | Болгар ш. | Х.1. | — | №28 таб. |
| | | | Куелган вакыты язылмаган ташлар. | | | |
| 52. | | | Татар Шәпкәсе ав. | Х.1. | — | №30 таб. |
| 53. | | | Болгар ш. | Х.1. | — | №31 таб. |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 54. | | | Коры Көрнәле ав. | Х.1. | — | №32 таб. |
| 55. | | | Иске Роман ав. | Х.1. | — | №33 таб. |
| 56. | | | Татар Калмаюры ав | Х.1. | — | №34 таб. |
| 57. | | | Иске Роман ав. | Х.1. | — | №35 таб. |
| 58. | | | — ,, — | Х.1. | — | №36 таб. |
| 59. | | | — ,, — | Х.1. | — | №37 таб. |
| 60. | | | Исләй ав. | Х.1. | — | №38 таб. |
| 61. | | | Иске Роман ав. | Х.1. | — | №41 таб. |
| 62. | | | Исләй ав. | Х.1. | — | №43 таб. |
| 63. | | | Иске Рәҗәп ав. | Х.2. | — | №39 таб. |
| 64. | | | — ,, — | Х.2. | — | №40 таб. |
| 65. | | | Чуваш Ялтаны ав. | Х.2. | — | №41 таб. |
| 66. | | | Иске Баллыкүл ав. | Х.2. | — | №42 таб. |
| 67. | | | Саурыш ав. | Х.2. | — | №43 таб. |
| 68. | | | Чистай ш. | Х.2. | — | №44 таб. |
| 69. | | | Иске Баллыкүл ав. | Х.2. | — | №45 таб. |
| 70. | | | Болгар ш. | Ю. | — | №7 таб. |
| 71. | | | Красный Ключ ав. | Ю. | — | №9 таб. |
| 72. | | | Болгар ш. | Ю. | — | №40 таб. |
| 73. | | | — ,, — | Ю. | — | №42 таб. |
| 74. | | | — ,, — | Ю. | — | №43 таб. |
| 75. | | | Батраки ш. | Ю. | — | №50 таб. |
| 76. | 7... | 13... | Ильдеряково ав. | Б. | — | №8 таб. |
| 77. | 7... | 13... | Яңа Дума ав. | Б. | — | №10 таб. |
| 78. | | | — ,, — | Б. | — | №11 таб. |
| 79. | | | — ,, — | Б. | — | №9 таб. |
| 80. | 7... | 13... | Саурыш ав. | Б. | — | №14 таб. |
| 81. | | | Балынгуз (Бүләр) | Х.М. | — | №1 таб. |
| 82. | | | Болгар ш. | Х.М. | — | №3 таб. |
| 83. | | | Матвеевка ав. | М.-ЭВ. | — | №1[22] -б.40. |

Таблицалардан күренгәнчә, болгар телендәге ташларның иң искесе 1288 елдан сакланып, 1358 елда юкка чыга. Язылу тарихлары сакланган ташларның саны 49 берәмлеккә җитә. Тагын да 33 ташның даталары бөтенләй юк, шул исәптән XIV гасырның беренче яртысына караганнарының елы язылган урыннары ватылган очраклар бар.

Идел буенда 1340-1345 елларда булып үткән чума авыруы вакытында даталы ташлар юк. Текстларында ел күрсәтелмәгән ташлар нәкъ шул дәвергә карыйлар булса кирәк. Аларда үлү вакыты күрсәтелмәүнең сәбәбе шушы үләт белән бәйле бер кара ышану аркасында килеп чыккан дип уйларга нигез бар.

Ташларның таралышы һәм куелыш динамикасы Алтын Урда дәверендә Болгар олысының шактый бай тормыш белән яшәгәнлеген күрсәтә.

Шунысы игътибарга лаек — Кама аръягындагы иң беренче ташлар гарәп телендә дә язылып куела башлаган. Аны түбәндәге таблицадан күреп була (Даталары язылган ташлар саны):

| Ел | Болгар телендә | Болгар-татар телендә | Татар телендә | Гарәп телендә |
|---|---|---|---|---|
| 1283 | 1 | | | 1 |
| 1388 | 1 | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1291 | 1 | | | 1 |
| 1294 | 1 | | | |
| 1299 | 1 | | 1 | 1 |
| 1300 | 1 | | | 1 |
| 1305 | 1 | | | |
| 1307 | 1 | | | |
| 1308 | 1 | 1 | | |
| 1309 | 1 | | | |
| 1310 | 1 | | | |
| 1311 | | 1 | 1 | |
| 1314 | 1 | | 1 | |
| 1315 | 1 | | | |
| 1316 | 2 | | | |
| 1317 | 3 | | 1 | |
| 1318 | 3 | | | |
| 1320 | 3 | | | |
| 1322 | 1 | | | |
| 1323 | | | 1 | |
| 1324 | 4 | | | |
| 1325 | 3 | | | |
| 1326 | 1 | | | |
| 1327 | 1 | | | |
| 1328 | 1 | | | |
| 1329 | 1 | | | |
| 1330 | 1 | 0 | | |
| 1333 | 2 | 3 | | |
| 1335 | 2 | | | |
| 1337 | | | 1 | |
| 1341 | 1 | 1 | 1 | |
| 1342 | | 1 | | |
| 1345 | | 1 | | |
| 1346 | 1 | 1 | | |
| 1347 | 2 | | | |
| 1348 | 1 | | | |
| 1349 | 2 | 1 | | |
| 1350 | | 1 | | |
| 1351 | 1 | 1 | | |
| 1353 | | | | |
| 1356 | 2 | | | |
| 1357 | | 2 | | |
| 1358 | 1 | | | |

Китерелгән таблицадан күренгәнчә, Кама аръягында гарәп һәм болгар телләрендә язылган эпитафик язмалар XIII гасырда бер үк чамада булган.

XIV гасырның башыннан 1330 елларга кадәр болгар телендәге ташлар сан ягыннан күпчелекне тәшкил итәләр. Болгарча — 44, татарча — 5, болгар-татар телендә катнаштырып язылган 2 таш билгеле, 1330 елдан соң татар телендә язылган ташларның саны сизелерлек арта: болгарча — 24, татарча — 10, гарәпчә — 2 дип билгеләнде.

Бу фактлар Идел буенда мөселман болгарларда татарлашу процессының XIII гасырда ук башланган һәм 1360 елларда төгәлләнгәнен сөйлиләр. Югыйсә, урыс елъязмалары Болгар һәм Җүкәтау шәһәрләренең этник ягын күрсәтеп: “татарлар” һәм “бисерманнәр” дип атамаслар иде.[23]

Болгарларның татарлаша башлавына Болгар шәһәренең 1243-1250 еллар арасында Алтын Урда дәүләтенең башкаласы булып торуы да этәргеч була. Болгарда рәсми дәүләт аппараты урнашып, татар теле дәүләт теле булып китә. Урта Азия якларыннан килгән төрки телле татар чиновниклары, сәүдәгәрләре Болгар, Җүкәтау, Бүләр шәһәрләрендә утырып та калганнар һәм шушы өч шәһәр татарлашу үзәкләре булып торалар. Аларда, кайберәүләр уйлаганча, монгол телле, будда диненә табынган монголлар түгел, ә мөселман динендәге, төрки телдә сөйләшүче татарлар утырып кала.

Татарлаша бару процессын 1281-1358 еллар арасында язылып куелган болгар телендәге эпитафия текстларыннан ук күреп була. Иң беренче чиратта, бу процесс мәҗүси кеше исемнәрендә күренә. Андый исемнәр һәр халыкның үз тел материалларыннан ясалган була. Билгеле, татар теле материалында ясалган кеше исемнәре бүгенге мари, удмурт, чувашларга күптән кереп, аларда XX гасырның беренче чирегенә кадәр актив кулланылышта булганнар. Бу хәл болгарлар белән дә шулай булган. Гәрчә болгарлар күптән мөселман булсалар да һәм күпчелеге болгар теленең эчке законнарына байсындырылып, деформацияләнгән гарәп-фарсы исемнәре йөртсәләр дә, аларга татарлар тәэсире белән татар-төрки исемнәре дә керә барган. Мәсәлән, Ф,Хәкимҗанов китапларында бирелгән исемнәр күрсәткече дә моңа материал бирә:

“Язык эпитафий волжских булгар”
китабыннан

Айбикә — әгәр болгар телендә булса, ул исемнең нигезе Айых яки уйых булыр иде. Исемнең икенче өлеше дә болгар социаль термины түгел.

Айу — төрки-татар исеме, чувашча аюны “упа” дип атыйлар.

Алып хуҗа — чувашча Улап.

Алыптай — Чыгытай, Каратай, Чемтай кебек татар исемнәре мәгълүм.

| | | |
|---|---|---|
| Алп | | Ураз |
| Алтын Берте | - чув.Ылтăн | Куванчы |
| Алтын бу | - чув.Ылтăн | Котлуг бәк |
| Алкыз | - чув.Йăм хĕрлĕ хĕр | Сокман |
| Амат хуҗа | | Табаҗ |
| Ар хуҗа | | Татар Бәлтүк |
| Аслан | | Тәмир |
| Байыш | - чув.Пуян +.,Пурлахла... | |
| Байкара | - чув. Пуян+хура | Орым Алып |
| Бәктемир | - чув.Пик+тимĕр | Чәләби |
| Бәлтүләк | | Җалавыр |
| Салар | | һ.б. |
| Бөҗәк | | (Бу исемлектәге |
| | | дистәләрчә |
| Бураш бәк | | бүтән |
| Ибраш | | татар-мөселман |
| Йулламыш | - чув. Çул+? | исемнәрен |
| Мамык | | китереп |
| Мәмәт | | тормадык) |

Эпитафия текстларында антропонимнар янында кулланылып килгән социал терминнарның болгар теленә Алтын Урдада татар теленнән ныклап һәм күпләп керүләре хакында сөйлиләр. Кызык ки, социаль терминнар исемнең алдында да, артында да килә ала һәм кайбер очракта татар социаль термины болгар теле спецификасына да буйсындырыла. Мисаллар.[24]

1) бик//бәк

Бураш бик, Булемшак бик, Гомәр бик, Муса бик, Хәсән бик һ.б.;

2) би//бий

Сөләйман би;

3) мәлик

Шаһем мәлик, Әр(ир) хуҗа мәлик, Сәфәр мәлик;

4) Белем, битик

Битек тау — Зеленодол р-ны топонимы,;

гыйлем, чәләби — чув вĕрĕннĕ

Әләмир белем, Вәвәкер (Әбүбәкер?) чәләби, Исмәгыйль гыйлем;

5) инал (князь) (чувашча аңа тәңгәл сүз юк.)

Мир Ибраһим инал.;

6) Шәйех (чувашча аңа тәңгәл сүз юк.)

Мөхәммәд шәйех әл-Кардари; Шәйех зийарәти.;

7) Сакый (чувашча аңа тәңгәл сүз юк.)

Биккә сакый.;

8) әлчи, әлти (татар этнонимы — алчи)

Сәнәҗ әлти, Фатыйма әлчи,

Әфәк әлти, Сабир әлчи,

Җәкәр әлти, Хаҗи әлчи;

9) хатун (хатын) — чув. арăм, хĕрарăм

Сәрә хатун;

10) Хуҗа (феодал) — чув. Хуçа (хозяин)

Алып хуҗа, Хуҗа Әхмәт,

Гали хуҗа, Хуҗа Бәйрәм,

Әбүбәкер хуҗа,

Әмәт хуҗа,

Әтрәҗ хуҗа,

11) Хаҗи (паломник)

Гали хаҗи бик әл-Болгари,

Әхмәт хаҗи,

Хаҗи Хөсәйен бик;

12) Тамгачы (таможник) — чув. тăмха — ......паллă......

Тамгачы Ибраһим

13) Алтынчы (ювелир) — чув. ювелир

Алтынчы Шәһидулла;

14) Казый (судья) — чув. судья

Карсак казый, Маҗар казый.

Китерелгән социаль терминнарның күпчелеге бөтен Алтын Урда татарлары җәмгыяте өчен мәгълүм һәм бүгенге татар әдәби теленең актив лексикасын тәшкил итәләр; чуваш телендә алар юк.

Тәхәллүсләр

Таш текстларында очрый торган тәхәллүсләр Болгар олысы халкының киң икътисадый бәйләнешләрен күрсәтәләр. Аларның бер өлеше инде 1243 елга кадәр (XI гасырдан) мәгълүм була. Мәсәлән, текстларда очрый торган Йувар атамасын без башка галимнәр кебек “дружинник” дип хисапламыйча, Төньяк Уралга, Юра//Югра җирләренә йөрүче болгар сәүдәгәрләренең тәхәллүсе дип хисаплыйбыз. Безнең бу хакта мәкаләбез матбугатка чыккан иде.[25]

Эпитафия телендәге тәхәллүсләрне географик пунктларга карап Урта Азия, Кавказ, Алтын Урда, Болгар олысы атамалары белән бәйләргә нигез бар. Бу атама — тәхәллүсләрдә XIII-XIV гасыр татар әдәби теленең лексик байлыгын тәшкил итеп, болгар теленең татарлаша бару күрсәткечләре булып торалар.

1) Болгар олысы белән бәйле тәхәллүсләр:

а) Болгар: Йуныс әл—Болгари, Болгари Муса, Мансур әл-Болгари, Болгари Салар, Хөсәйен Болгари;

б) Йөри // Йори // Йувари: Ир-Әхмәт Йувари, Йувари Давыт, Йувари Көч, Йувари Әхмәт, Гали Йувари, Исмәгыйль Йувари, Хәсән Йувари, Хөсәйен Йувари, Ягкуб Әйүб Йувари, Әбүбәкер Йувари, Әтрәҗ Йувари;

в) Бүләр: Мөн Бүләр Балым Ир-Әхмәт Йувари

г) Сивар (Сувар): Сивар Йалый хуҗа, Ибраһим әс-Сивари, тамгачы Ибраһим әс-Сивари, Сивари Әзнәб.

д) Көйек: Муса Көйек.

е) Орым: Орым Алып, Орым Мөхәммәд.

ж) Татар: Татар Бәлтүк.

з) Тимерчи: Тимерчи Мәмли.

и) Төрекмән: Төрекмән Мөхәммәд.

к) Тухчы: Тухчы Исмәгыйль.

л) Тәмти: Хаҗи Тәмти.

м) Ырыс: Ырыс Сираҗи.

н) Мукшы: Мукшы Бизан әл-Болгари.

2) Урта Азия белән бәйле тәхәллүсләр:

а) Сәмәрканд шәһәре: Хәсән Сәмәрканди,

б) Фирганә өлкәсе: Җафар ага әл-Фирганәҗи,

в) Җәнд шәһәре: Мөхәммәд әл-Җәнди,

г) Хорәсән өлкәсе: Мөбәрәкшаһ Курсани,

д) Кәрдар шәһәре— Мөзхәммәд шәйех әл-Кәрдари.

3) Кавказ белән бәйле тәхәллүсләр:

а) Шәмахә шәһәре: Ырыс әш-Шәмахи,

б) Ширван шәһәре: Садретдин әш-Ширвани.

Текстлардагы башка лингвистик үзенчәлекләр.

XIII-XIV гасырлардан калган Урта Идел буендагы кабер ташларындагы текстларның теле лингвистик яссылыктан беренче мәртәбә системалы рәвештә Ф.Хәкимҗанов тарафыннан тикшерелде. Без аның материалларын ышанычлы санап, беренче чиратта аның чыганакларына таянабыз. Ул, текстларның

фонетик, морфологик һәм лексик үзенчәлекләрен ныклап тикшереп матбугатка чыгарса да, без үзебезнең анализ процессында аларны беркадәр кабатлап, башкача фикерләребезне ныгытуда файдаланырбыз.

а) Текстларның графофонетик үзенчәлекләре хакында.

Алда әйткәнебезчә, XIII-XIV гасырларда болгар телендә язылган текстлар болгарларның инде XIII гасырда ук татарлаша баруларын күрсәтәләр. Галимнәр болгар теленең чуваш теленә якынлыгын күптән таныганлыктан, без бу эш процессында соңгысының материалларын җәлеп иттек.

Болгар теленң татарлаша баруы күрсәткече булып аның, чуваш теленнән аермалы буларак, яңгырау тартыкларга ия булуын һәм сузык авазлар башкалыгын күрсәтергә кирәк.

| № | Болгарча | Татарча | Чувашча |
|---|---|---|---|
| | Сузыклардагы аермалар | | |
| 1. | алты | алты | ултă |
| 2. | айых | айы | уйăхĕнче |
| 3. | авли | улы | ывăл |
| 4. | алтмыш | алтмыш | утмăл һ.б. |
| | Китерелгән мисаллар болгар теленең чуваш теленә кардәшлеге барлыгын күрсәтә, аның татар теле тәэсирен кичергәнлеген раслый. | | |
| 5. | белим | биш | пиллĕк |
| 6. | билем | белем | пĕлни |
| 7. | бир | бер | пĕр |
| 8. | болтуй | булды | пулнă |
| 9. | җийати | җиде | çичĕ |
| 10. | җүр | йөз (җөз) | çер |
| 11. | тохур | тугыз | тăххăр |
| 12. | шуw | су (суw) | шыw һ.б. |

Морфология өлкәсендәге якынлык һәм аермалар

| № | Болгарча | Татарча | Чувашча |
|---|---|---|---|
| 1. | дөнйаран | дөньядан | тĕнчеран |
| 2. | шывнә | суына | шывна |
| 3. | һири | кызы | хĕрĕ |
| 4. | зираты | зираты | масарĕ |
| 5. | болтый | булды | пулнă |
| 6. | голамасамна | голамәләрне | вĕреннĕ çынсемна |
| 7. | масҗедсамнә | мәсҗедләрне | мечĕтсемна |
| 8. | галимларга | галимләргә | ? |
| 9. | масҗедлар | мәсҗедләр | мечĕтсем |
| 10. | тохурваным | туксанынчы | тăхăрвуннăмĕш |
| 11. | тондый | түнде | куçсĕ, куçре |
| 12. | дөнйадан | дөньядан | тĕнчеран |

Морфологик яктан караганда, текстларда чуваш теле өчен специфик булган — ран морфемасы бик еш, һәм — сам (ягъни күплек форманты — лар)

үтә сирәк очрыйлар. Болгар теленең бу морфемалары аның чуваш теленә кардәшлеген күрсәтәләр. Мисаллар бу өлкәдә татар теленең болгар теленә генә түгел, чуваш теленә дә көчле тәэсире хакында сөйли. Ләкин бу өлкәдә болгар морфемаларының тотрыклырак саклануына игътибар итәргә кирәк. Бу аеруча XIV гасырның беренче чирегендә күзәтелә.

Болгар телендәге эпитафияләрне тикшерүче Ф.С.Хәкимҗанов андагы “болтуй” сүзенең язылышында төрле орфографик аермалар күреп, бу очракта аны диалектлар чагылышы дип нәтиҗә чыгара.[26] Без исә бу күренешне болгар теленең югала бару, аның орфографик нормалары буталу белән бәйләп карыйбыз. Шуның белән берлектә болгар телендәге язу традицияләре бик йомшак булып, аның язу теле традициясе булмаганлыгы да ышандыра.

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1. | بَلطوى | bolṭï | булды |
| 2. | بلطوٗى | bolṭï | булды |
| 3. | بُلطَوٗى | boltï | булды |
| 4. | بلطى | bolṭï | булды |
| 5. | بَلطٗي | bolṭu | булды |
| 6. | بالطو | bolṭu | булды |
| 7. | بلجى | bolči | булды |
| 8. | بولدى | boldï | булды |

Хәзер инде болгар һәм болгар-татар катнаш телләрдә язылган үрнәкләрне карап үтик.

1) “Һиҗрәтран алты җүз тохурваным җал” — Болгар шәһәрендә 1291 елның августында куелган текст (Юсупов“ 3 таб).

2) “Галимләргә тәрбийәт кыйлган, заһидларга сүгән мәсҗедләрне гыймарәт кыйлган, үкүш һәйератлыйг Маҗар казый углы Исмәгыйль зийарәти бу .....”

“вафат болтый тарих җийати җүр ван бир җал, рәҗәб айых җирем әкиш күән әт”. — Чистай шәһәре зираты, 1311 елгы таш (Хәкимҗанов, 2 — 94-95 бб).

3) “Рабигыл-әүвәл айых (а)хырында (ва)фат болтый” — Нижнекамск р-ны, Урта Чаллы авылы янында, 1323 ел (Хәкимҗанов, 2-146-147 бб).

4) “...изге рахим Аллаһ тиләр — вол хилер, кем керсә вохыр Фатыйха сурәси вал”. Бу соңгы мисалны без “...изге рәхим Аллаһ теләр, ул килер, кем керсә укыр фатиха сурәси ул” — дип аңлыйбыз (Х.2. -б.128-129). Мисалларда татар, чуваш сүзләре катнашып беткән. Моны диалектизм дип бәяләп булмый инде.

Эпитафия текстларында анлаут хәреф буларак очрый торган “و”хәрефнең укылышы хакында үзебезнең фикерне әйтеп үтү кирәк.

Эпитафия текстларындагы язылышлар үрнәкләренә мөрәҗәгать итик. Мәсәлән:

1) جَياتِجوَرجيارموُجمجل
Ф.Хәкимҗанов аны:
ǯėti ǯör ǯėrme üčüm ǯïl
дип укый (Х.1.-8);

2) ايخونسكركوان
ajxï on säker kön (X.1.-11);
3) تاريخ جياتجوروو وطرجال
tarixa ǯėti ǯür wä oṭur ǯa°l (X.1.-13);
4 ) تاريخجياتجوروو وطرجال - tarixa ǯeti
ǯür wä oṭur ǯa°l (X.1.-14);
5) تاريخجيتجورونجال - tarix
ǯite ǯür on ǯa°l (X.1.-4);
6) تاريخجياججروو وطروجمجال - tarix
ǯečï ǯeri wä oṭur očem ǯa°l..эti (X.1.-15);
7) جرموجمكون (X.1.-15)
ǯerme očem kün;
8 ) وفت - wäfät (X.1.-15), وفات - wafat (X.1.-22);
9) ورمالب - Urum Alp (X.1.-3).

Мисалларны чагыштырсаң, ووطر, وجم, ون ягъни ун, өченче, утыз саннарының һәм "вафат", "Урум" сүзләренең болгар телендәге язылышларын укуда каршылык күзгә ташлана. Аларга беркадәр анализ ясап карыйк.

Болгар телендәге катлаулы саннар язылышын укыганда, "вә" теркәгеченең бер сан янында гына килүе, башка саннар янында кулланылмавы ووطر сүзен wä otur дип түгел, бәлки wotur, ягъни чуваш телендәге ватар (ягъни утыз) рәвешендә укырга кирәклеген күрсәтә.

Шулай ук وفات - вафат (wafat) һәм ون (on) وجم (očem) сүзләренең укылышында принципсызлык күзәтелә. бу сүзләр вутыр, вафат, ван, вачем рәвешендә укылырга тиеш була. Алдагы ватар сүзе укылышы белән боларның укылышы бер система тәшкил итәләр. Югыйсә, "вә отур" рәвешендә укысак, وجم сүзен дә "вә җем" рәвешендә укырга тиеш булабыз.

Шулай ук "او" һәм "وا" графофонемаларын укуда да принципсызлык күзәтелә.

Мәсәлән اوماراول - Ümär oulï (X.1.-15).

اوراز اول - Ouraz oulï (X.1.-3) — мисалларында бер ук графема ике төрле укыла "Үмәр оулы" икенчесе Оураз оулы", مجرقضاوغلى - Maǯar qaḍi oǥï (X.2.-3), ونبر - onbir (X.2-3) قرقاوجدا qirq üčdä (X.2-10) جياتجوروانبر - ǯeti ǯür onbir (X.2-3). Китерелгән мисалда "җиде йөз унбер" саны бар. Андагы "Onbir" санының укылышы башка мисаллар белән принципка туры килми.

Димәк ки, мисаллардан күренгәнчә "او" графофонемасы сүз башында о/ /у//ө//ү авазларын белдерү өчен кулланыла. Сүз башында "و" хәрефе "в(ә)" фонемасын аңлата: вафат, вотыр, ван һ.б.

ЙОМГАК

I. Болгар олысы эпиграфикасы географик таралыш ягыннан тарихи өч зонага бүленеп, аның иң игътибарга лаегы Кама аръягындагы эпитафик текстлар дип саныйбыз.

II. Текстлар болгар, татар, гарәп һәм болгар-татар катнаш телләрендә язылганнар.

III. Текстлардагы гарәпчә “و” графофонемасы сүз башында булганда традицион укылыш тәртибенә буйсына, бу аеруча аның кабер ташлар текстында очрый торган ووطر, ягъни вотыр -отыз/утыз сүзенең язылышында күзәтелә. Шунлыктан وفات وجم, وَلِت, وَن, وان кебек сүзләрнең язылышын вачем, валәт ван, ван, вафат́ (Wacem, wan, wan, wafat) рәвешендә укырга туры килә. Укылышта беркадәр чуваш теле нормалары чагыла һәм әлеге укылыш система буларак дөреслеккә туры килә. Бу исемлеккә чувашчага якын булган һир, айых, тохур, тохурван һ.б. сүзләр дә кереп, бердәм система тәшкил итәләр.

IV. Болгар телендә һәм катнаш болгар-татар телләрендә язылган ташларның телендә XIII гасырдан ук фонетик яктан сузык авазлар ا = а, ә; او = о,у катнашында башланган сүзләр татар теленә күчешне белдерәләр. Тартыклардан ج = җ, ب = б куллану шулай ук татар теле үзенчәлекләренә туры килә. Анлаут графофонема итеп و = в (w) куллану чуваш теле өчен хас сыйфат.

V. Морфемаларда -меш, -сам, -ран, -ем кебек чуваш теленә хас кушымчалар куллану, аның болгар теленең кардәше икәнлеген күрсәтә. Ләкин инде татар күплек форманты -лар, болгар теленең -сам(сем) формантын кысып чыгара язган. Тәртип саннары язылышындагы аерымлыклар XIII-XIV гасыр болгар теленең борынгы баба теленнән күптән аерылганын һәм татар теле йогынтысында яшәгәнлеген күрсәтәләр.

VI. Лексик яктан татарлаша бару процессы антропонимнар, титуллар, гыйлем-китап терминнары, тәхәллүсләр, топонимнар мисалында чагыла. Туганлык терминнарында һәм саннарда чуваш теле лексикасы белән охшашлык күзәтелә: — һир -хир(кыз), әчкә — ата, ван — ун, айых — ай, вал — ул, ваглы — углы, вутыр — утыз, җүр — җүр(йөз), вәчем — өченче, билеҗ — пиллек — бишенче.

VII. XIV гасыр башында ук татар һәм болгар телләре катыштырып язылган текстлар күзгә ташлана. Катнаш телләрдә язылган ташлар хәзерге Кама аръягында тарала башлаган (Болгар олысында).

XIII. Саф татар телендәге ташлар XIII гасырда ук күренеп, 1330еллардан соң сан ягыннан арта башлыйлар. Әгәр 1333 елга кадәр татар телендә язылган 8 таш мәгълүм булса, 1340-1360 еллар арасында 13 таш тексты мәгълүм. 1360 елдан соң фәкать татар телендә язылган ташлар гына мәгълүм.

Татар теле бу елларда бер болгар теленә генә түгел, XIV гасырда Болгар шәһәрендә яшәгән әрмәннәргә дә тәэсир иткән. Болгар шәһәрендә сакланган әрмән каберташ язмаларындагы антропонимнарда, титулларда татарлык, мөселманлык галәмәтләре күзгә ташлана. Мәсәлән. “Сары хатун”,

“Аваг” — (в году) 770 (1321 ел),

“Аваг” — 748/1335 ел,

“Ягуб” — 570/1121ел(?),

“Овсен” — 767/1318 ел,

“Турчан-Мелик” — 767/1318 ел һ.б.[27]

IX. Язулы мөселман кабер ташлары кую гадәте Көнчыгыш Европада фәкать Алтын Урда дәверендә генә башлана. Бу гадәт борынгы төрки каганатлар дәверендә күренә башлап, XII-XIII гасырларда Караханилар

дәүләте җирләрендә күтәрелә. Шушы гадәтне Батый хан гаскәрен тәшкил иткән Карахани, Киймәк каганлыгы, Хәрәзем дәүләте мөселман-татарлары Көнчыгыш Европага да алып киләләр. Кабер ташларының үрнәкләре Кавказ, Кырым, Түбән Идел һ.б. урыннарда булулары хакында хәбәрләр бар.[28] Фәнни матбугатта мөселман каберләре өстенә язылып куелган таш язмаларның әүвәлге Караханилар дәүләте җирләрен тәшкил иткән хәзерге Кыргызстан, Көнчыгыш Төркестан, Казагыстан һәм Үзбәкстан дәүләтләренең көньяк өлкәләрендә табылып, өйрәнелүгә багышланган хезмәтләре күренә.[29] Куфи язуы белән гарәп телендә язылган, төркиләргә нисбәтле кабер ташлары Х гасырның икенче яртысында (мәсәлән, 348 ел һиҗри, руми 959/960) Караханилар җире булган Бохара, Сәмәрканд төбәкләрендә сакланганлыгы хакында хәбәрләр бар.[30] Караханиларның акча сугу традициясе үскән булган[31] һ.б. Көнчыгыш Европага 1236 елда килгән Бату хан гаскәренең төп өлешен тәшкил иткән Караханилар, Кимәк каһанлыгы, Хәрәзем дәүләтләре халкының варислары, 1243 елда Алтын Урда дәүләтен төзүгә керешеп, үзләренең мәдәниятләрен яңа урында үстерүне дәвам итәләр.

XIII гасырда Урта Иделдә куелган куфи хәрефләре белән гарәп телендә язылган ташлар, барлык материалның яртысын тәшкил итәләр. Бер үк вакытта татар һәм болгар телендә язылган текстлар барлыкка килгәннәр.

Болгар телендәге текстлардагы орфография чуарлыгы һәм аларның татарлашу тенденциясе беренчесенең эшләнгән язу традициясе булмаганлыгын, ягъни язуга яңа җайлаштырылуын күрсәтә. Димәк, болгар теле язуы кагыйдәләре XIII гасыр ахырында да, аннан соң да җитәрлек эшләнмәгән хәлдә калган. Болгар дәүләтендә Х гасыр башыннан язу теле булып фәкать гарәп теле хөкем сөреп килгән булган, Алтын Урда дәүләте төзелгәч, анда ерак язу традициясенә ия булган әдәби татар теле рәсми тел булып таныла, шул ук вакытта болгар теленә дә язуга беркетелергә мөмкинлек туа.

X. XIII-XIV гасыр болгар теле, һичшиксез, бүгенге чуваш теленә кардәш тел. Ләкин болгар теле борынгы чуваш теленнән XIII гасыр башыннан да соң аерылмаган. Әлеге тел татар теле тәэсирендә үзенчәлекләрен тәмам югалтып, аның белән кушылып китә.

Борынгы чуваш теле исә бер яктан борынгы мари теле белән бәрелешкә килеп керә, икенче яктан аңа да татар теленең даими йогынтысы үсә барган. Чуваш теле XVII-XIX гасырларда татарлаша бару чорына керә.

XI. XII-XIV гасырларда Болгар олысына татар этносының даими үтүе болгарларның тел ягыннан татарлашуына китерә. Мөселман-болгарларның бүгенге чуваш халкына кардәшлек билгесе булган телләре юкка чыккан. Мәҗүси болгарлар исә чуваш халкының төп бабалары булып калганнар. Ихтимал, аларның икесенең дә мәҗүси бабалары культурасы бер булгандыр. Ләкин ислам диненә күчү һәр ике халыкның да тарихи-этник үсешенең аерылуына китереп, алар торган саен бер-берсеннән башка этник төркемнәр керә барып, кан кардәшлегеннән, рухи бердәмлектән ераклашканнар. Ахырда, мөселман болгарлар татар халкы составында ассимиляцияләнеп, этник берлек булып яшәүдән туктыйлар. Мәҗүси болгарлар исә марилар белән катнашып угро-фин мәдәниятына тагын да ныграк якынаялар. Татарлашкан болгарлар турында истәлек әле XVII гасырда сакланганга ошый. Урыс писцовая

кнәгәләрендәге татар авылларын “чуваш” дип атау шуның соңгы билгеләре булуга дәлил.

Искәрмәләр:

[1] *Юсупов Г.В.* Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. — М.-Л., Изд-во АН СССР, 1960. — Б. 8.

[2] *Юсупов Г.В.* Введение... -Б. 9.

[3] *Талат Текин.* Волго Булгар китабелери вә Волга булгарчасы. — Әнкара, 1988. — Б. 212.

[4] *Юсупов Г.В.* Введение... — Б. 59.

[5] Шунда ук. — Б. 54.

[6] Шунда ук. — Б. 69.

[7] *Хакимзянов Ф.С.* Язык эпитафий волжских булгар. — М.: Изд-во “Наука”, 1978. — 205 б.

[8] Шунда ук. — Б. 99.

[9] Шунда ук. — Б. 99.

[10] Шунда ук. — Б. 99.

[11] Шунда ук. — Б. 98.

[12] *Малов С.Е.* Булгарские и татарские эпиграфические памятники // Эпиграфика Востока I. — М.-Л.: Изд-во АН СССР, 1947. — Б. 38-45; Эпиграфика Востока II. — М.-Л.: Изд-во АН СССР, 1948. — Б. 41-48; *Юсупов Г.В.* Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. — М.Л.: Изд-во АН СССР, 1960. — 322 б.; *Булатов А.Б.* Эпиграфические памятники Закамья XIV века // НИИ при Совете Министров Чувашской АССР. Ученые записки. Выпуск XXXVI. — Чебоксары, 1967. — Б.198-215; *Хакимзянов Ф.С.* Язык эпитафий волжских булгар. — М.: “Наука”, 1978. — 205 б. *Хакимзянов Ф.С.* Эпиграфические памятники Волжской Булгарии и их язык. — М.: “Наука”, 1987. — 191 б; *Hakimzjanow F.S.*(Kazan).New WolgaBulgariay inscriptions // ActaOrientaliaHunq.Tomus (I). — 1986. — 173-177 pp. *KhalicowA.H.* and *Muhametshin Y.J.* (Kazan). Unpublis-hed Volqa Bulqarian inscriptions // Asta Orient. Hund Tomus XXXI. Fasc. I, 1977. — 107-125 pp.; *Мухаметшин Д.Г., Хакимзянов Ф.С.* Эпиграфические памятники города Булгара. — Казань: ТКИ, 1987. — 125 б.

[13] *МухаметшинД.Г., Хакимзянов Ф.С.* Эпиграфические памятники города Булгара. — Б. 60.

[14] *Әхмәтҗанов М.* Казан ханнары тарихыннан // Идел. — 1944. — №11. — Б.64-65.

[15] X.2. — кыскартмасы: *Хакимзянов Ф.С.* Эпиграфические памятники Волжской Булгарии и их язык. — М.: “Наука”, 1987.

[16] X.3. — кыскартма: *Hakimzjanov F.S.* Ntw Vjlga... // Acta Orientalia... Hunq. — 1986. — №1. — б.173-177.

[17] Ю. — кыскартма: *Юсупов Г.В.* Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. — М.-Л., 1960.

[18] X.M. — кыскартма: А.Х.Халиков һәм Җ.Мөхәммәтшиннарның инглиз телендә “Acta Orientalia Academiae”... Hunq. — 1977. — №1. — б.107-125. журналында басылган мәкаләсе;

[19] М. — ЭВ. — №2. — кыскартма: *Малов С.Е.* Булгарские и татарские эпиграфические памятники // ЭВ. 1948. — Вып.2.

[20] X.1. — кыскартма: *Хакимзянов Ф.С.* Язык эпитафий волжских булгар. — М., 1978.

[21] Б. — кыскартма: *Булатов А.Б.* Эпиграфические памятники Закамья XIV века // Ученые записки. — Выпуск 36. — Чебоксары, 1967.

[22] М.ЭВ. — №1. — кыскартма: *Малов С.Е.* Булгарские и татарские... // ЭВ., 1947. — Вып, 1.

[23] Источники по истории Татарстана. — Казань, 1993. — Б.8-10.

[24] *Мисаллар Ф.С.* Хәкимҗановның “Язык эпитафий волжских булгар”. (М.: Изд-во “Наука”, 1978) дигән китабының 188-191 битләрендәге сүзлекчәдән безнең укылышта алынды.

[25] *Ахметзянов М.И.* О двух булгарских словах из эпитафийных надписей // Язык утилитарных и поэтических жанров памятников татарской письменности. — Казань, 1990. — Б.113-117.

[26] *Хакимзянов Ф.С.* Язык эпитафий волжских булгар. — М., 1978. — Б.72.

[27] *Джанполадян Р.М.* Армянские надписи на Волге // Эпиграфика Востока. XXII — Л.: “Наука”, 1984, — б.73-79.

[28] *Крачковская В.А.* Неизвестный альбом по арабской и персидской эпиграфике // Эпиграфика Востока II. — М.-Л.: Изд-во АН СССР, 1948. — Б.19-40. *Проф.Бороздин.* Татар мәдәниятын өйрәнүгә яңа материаллар (1925 елның җәендә Иске Кырымда ясалган казулар) // Безнең юл. — 1925. — №9010. — Б.16-20; *Виноградов В.Б.* Тайны минувших времен. — М.: Изд-во “Наука”, 1966. — Б.143-147; *Челеби Эвлия.* Книга путешествия (Извлечения из сочинения турецкого путешественника XVII века). Вып.2. — М., 1979. — Б.140-141 һ.б.

[29] *Якубовский А.Ю.* Две надписи на севернем мавзолее 1152 г. в Узгенде // Эпиграфика Востока I. — М.-Л.: Изд-во АН СССР, 1947. — Б.27-32; *Дьяков М.М.* Несколько надписей на кайраках из Киргизии // Эпиграфика Востока II. — М.-Л., 1948. — Б.9-15; *Горячева В.Д., Настич В.Н.* Эпиграфические памятники Сафид-Булана XII-XIV вв. // Эпиграфика Востока XXII. — Л.: “Наука”, 1984. — Б.61-72.

[30] *Агаджанов С.Г.* Очерки истории огузов и туркемн Средней Азии IX, IX-XIII вв. — Ашхабад: Изд-во “Ылым”, 1969. — Б.183.

[31] *Агаджанов С.Г.* Очерки... — Б.187, (Агаджанов хезмәтендәге чыганакларга карaганда, Хәрәзем дәүләте җирләрендә 1065 елда мөселман татарлар яшәгәнлеге хәбәр ителә. — Кара: 227 бит).